Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты

Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

7 ноябрь, 2025 ел № 52

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннары йөрү урыннарын билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Уставы белән гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтенең сакланышын тәэмин итүче йорт хайваннарын йөртү өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен, күзләре күрмәүче инвалидны озата баручы эттән тыш, түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- халык күпләп җыелмый торган авыл җирлегендә, буш урыннар, торак секторлары һәм җәмәгать киңлекләре артындагы урыннар, аларның хуҗалары күзәтүе астында:

- Кощаково авылында Комсомол – Набережная урамнары арасындагы дамба;

- Кощаково авылы Ирбис заправкасының каршы ягындагы кырда;

- Иске Кощаково авылы ахырындагы кыр (Луговая һәм Солнечная урамнары арасында);

- Званка авылы башындагы карьер;

- Царево авылы башындагы басу.

Потенциаль куркыныч этләрне намордниктан һәм тезгеннән башка йөртү тыела.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова